ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 14 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 пунктының «е» пунктчасына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 17 (I өлеш), № 77 (I өлеш), «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон яисә «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга граждан-хокук шартнамәләренә таянып» сүзләрен «гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон яисә «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән граждан-хокук шартнамәләренә, «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган объектларга карата төзелгән концессия килешүләренә, «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның

7 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган объектларга карата төзелгән дәүләти-хосусый партнерлык турындагы, муниципаль-хосусый партнерлык хакындагы килешүләргә таянып» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2023 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 29 сентябрь
№ 88-ТРЗ